# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге составына керүче Татар Аксуы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

17.11.2023 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Лашчы авыл җирлегенең Татар Аксуы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Татар Аксуы авылында урам яктырткычларын сатып алу һәм алыштыру, юлларны төзекләндерү, җәйге чорда территорияне чабу өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2023 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 60 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 38 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашкан 38кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге составына керүче Татар Аксуы авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Югары Лашчы авыл җирлегенең Татар Аксуы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Татар Аксуы авылында урам яктырткычларын сатып алу һәм алыштыру, юлларны төзекләндерү, җәйге чорда территорияне чабу өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татар Аксуы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ Г.Х. Усманова

Югары Лашчы авыл җирлеге
башлыгы __________________ Г.Х. Усманова